КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2024 ел, 25 октябрь г.Казань № 921

Татарстан Республикасы дәүләт органнары хезмәткәрләренә һәм Татарстан Республикасы дәүләт учреждениеләре хезмәткәрләренә хезмәт командировкаларына бәйле чыгымнарны каплау турында

Россия Федерациясе Хезмәт кодексының 168 статьясындагы өченче өлеше нигезендә хезмәт командировкаларына бәйле түләүләрне тәртипкә салу максатларында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы дәүләт органнары хезмәткәрләренә һәм Татарстан Республикасы дәүләт учреждениеләре хезмәткәрләренә Россия Федерациясе территориясендә хезмәт командировкаларына баруга бәйле чыгымнарны каплау, әгәр Татарстан Республикасының башка норматив хокукый актларында башкасы билгеләнмәгән булса, түбәндәге күләмнәрдә гамәлгә ашырыла дип билгеләргә:

а) торак урын наемы буенча чыгымнар (хезмәт командировкасына җибәрелгән хезмәткәргә бушлай бүлмә бирелә торган очрактан башка) – тиешле документлар белән расланган факттагы чыгымнар, әмма тәүлегенә иң күбе 550 сум күләмендә. Әлеге чыгымнарны раслый торган документлар булмаганда – тәүлегенә 12 сум;

б) тәүлеклек өчен түләү чыгымнары – хезмәт командировкасында булган һәр көн өчен 200 сум күләмендә;

в) хезмәт командировкасы урынына бару һәм аннан даими эш урынына кире кайту чыгымнары (юл йөрү документларын рәсмиләштерү буенча хезмәт күрсәтүләр өчен түләүне, поездларда урын-җир әйберләреннән файдаланган өчен чыгымнарны кертеп) – юл йөрү документлары белән расланган факттагы чыгымнар, әмма иң күбе юл йөрү кыйммәте күләмендә:

тимер юл транспорты белән – тиз йөри торган фирма поездының купе вагонында;

су транспорты белән – даими транспорт линияләренең һәм пассажирларга комплекслы хезмәт күрсәтү линияләренең V төркемдәге диңгез судносы каютасында, барлык элемтә линияләренең II категориядәге елга судносы каютасында, паром белән елга кичү судносының I категориядәге каютасында;

һава транспорты белән – эконом класс салонында. Татарстан Республикасы дәүләт органнары хезмәткәрләренең һәм Татарстан Республикасы дәүләт учреждениеләре хезмәткәрләренең командировка урынына бару һәм (яки) киресенчә даими эш урынына кайту өчен һава транспортыннан файдаланганда, юл йөрү документлары бары Россия авиакомпанияләре яки башка дәүләтләр – Евразия икътисадый берлеге әгъзалары авиакомпанияләре рейсларына гына рәсмиләштерелә (сатып алына) (әгәр әлеге авиакомпанияләр хезмәткәрнең командировка урынына кадәр пассажирлар йөртүне гамәлгә ашырмаган яисә очу датасына хезмәткәрнең командировка урынына һәм (яки) киресенчә кайту урынына кадәр әлеге авиакомпанияләр рейсына юл йөрү документларын, алар булмау аркасында, рәсмиләштерү (сатып алу) мөмкинлеге булмаган очраклардан тыш);

автомобиль транспорты белән – гомуми файдаланудагы автотранспорт чарасында (таксидан башка);

башкарылган чыгымнарны раслый торган юл йөрү документлары булмаганда – юл йөрүнең минималь кыйммәте күләмендә:

тимер юл транспорты белән – пассажир поездының плацкарта вагонында;

су транспорты белән – даими транспорт линияләренең һәм пассажирларга комплекслы хезмәт күрсәтү линияләренең X төркемдәге диңгез судносы каютасында, барлык элемтә линияләренең III категориядәге елга судносы каютасында;

автомобиль транспорты белән – гомуми типтагы автобуста.

2. Әлеге карарның 1 пунктында билгеләнгән күләмнәрдә чыгымнар тоту Татарстан Республикасы дәүләт органнары һәм Татарстан Республикасы дәүләт учреждениеләре тарафыннан аларга хезмәт командировкалары өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан бүлеп бирелгән яисә (әлеге ассигнованиеләрне тулы күләмдә файдаланган очракта) Татарстан Республикасы бюджетыннан аларны карап тотуга бүлеп бирелгән акчаны экономияләү исәбеннән башкарыла.

3. Әлеге карарның 1 пунктында билгеләнгән күләмнән артыграк чыгымнар, шулай ук хезмәт командировкалары белән бәйле башка чыгымнар (алар эш бирүченең рөхсәте яисә аңа мәгълүм булып хезмәткәр тарафыннан башкарылган очракта) Татарстан Республикасы дәүләт органнары һәм Татарстан Республикасы дәүләт учреждениеләре тарафыннан тиешенчә Татарстан Республикасы дәүләт органының, Татарстан Республикасы дәүләт казна учреждениесенең бюджет сметасын, Татарстан Республикасы дәүләт бюджет (автоном) учреждениесенең финанс-хуҗалык эшчәнлеге планын үтәү барышында барлыкка килгән акчаны экономияләү исәбеннән каплана.

4. Татарстан Республикасы дәүләт органнары хезмәткәрләренә һәм Татарстан Республикасы дәүләт учреждениеләре хезмәткәрләренә чит ил дәүләтләре территориясенә хезмәт командировкаларына баруга бәйле чыгымнарны каплау Татарстан Республикасы дәүләт органнары һәм Татарстан Республикасы дәүләт учреждениеләре тарафыннан федераль дәүләт органнары хезмәткәрләре һәм

федераль дәүләт учреждениеләре хезмәткәрләре өчен билгеләнгән тәртиптә һәм күләмнәрдә гамәлгә ашырыла.

5. Хезмәт командировкасыннан кайткач, хезмәткәр эш бирүчегә өч эш көне эчендә хезмәт командировкасына бәйле рәвештә тотылган суммалар турында хисап бирергә тиеш. Хисапка торак урын наемы турында документлар, юл йөрү буенча факттагы чыгымнар (юл йөрү документларын рәсмиләштерү һәм поездларда урын-җир әйберләре бирү буенча хезмәт күрсәтүләр өчен түләүне дә кертеп) һәм хезмәт командировкасына бәйле башка чыгымнар турында документлар беркетелә.

6. Әлеге карар Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренә, Татарстан Республикасының дәүләт вазыйфаларын биләүче затларга, шулай ук «Татарстан Республикасының Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды» дәүләт учреждениесе хезмәткәрләренә кагылмый дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин